| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
| --- | --- | --- |

| **РЕШЕНИЕ**<br>10 ноября 2015 года | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>№ 21 |
| --- | --- | --- |

2016 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең бюджет проектын төзү үзенчәлекләре һәм раслау, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О. П. Дегтева мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2013 елның 14 ноябрендәге 199 номерлы карары белән расланган бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 2016 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты проектын (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында Зеленодольск шәһәре Советы карары проекты) төзү һәм раслауга карата нигезләмә нормаларының план чорына Зеленодольск шәһәре Советына күрсәтелгән проект белән бер үк вакытта Зеленодольск шәһәре Советы карары проекты белән бер үк вакытта план чорына документлар һәм материаллар тапшыруны туктатырга (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразыннан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләреннән тыш).

2) Нигезләмәнең 5 статьясындагы 2 пунктында «Зеленодольск шәһәре» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) Нигезләмәнең 8 статьясында:

3.1) «Татартан Рспубликасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба- шәһәр Башкарма комитеты)» сүзләрен "Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – район Башкарма комитеты)" сүзләренә алмаштырырга»;

3.2) “Зеленодольск шәһәре финанс органы (алга таба – шәһәрнең финанс органы)” сүзләрен “Зеленодольск муниципаль районының финанс органы (алга таба – районның финанс органы)” сүзләренә алмаштырырга;

4) Нигезләмәнең 9, 15, 16, 19, 20, 24, 26, 29, 30, 33-35, 46-48, 50, 53 статьяларында "шәһәр Башкарма комитеты» сүзләрен тиешле килештә “район Башкарма комитеты” сүзләре белән тиешле килештә алмаштырырга;

5) Нигезләмәнең 5, 9, 16, 19, 20, 24, 25, 28, 32, 34-37, 39, 40, 41, 43, 44, 46, 48, 50, 53 статьяларында «шәһәрнең финанс органы» сүзләрен тиешле килештә «районның финанс органы» сүзләре белән тиешле килештә алмаштырырга;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Зеленодольск шәһәре Советы 2015 елның 28 сентябрендәге 8 номерлы «Зеленодольск шәһәре Башкарма комитетын бетерү турында» карары, әлеге карарның 1 пунктындагы 2-5 пунктчаларының гамәлдә булуы үз көченә кергән көннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск шәһәре Советы законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**